ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ
КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

22.02.2023 г. Казань № Пр-20/2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыклары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 19.03.2020 № 40;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 19 мартындагы 40 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы

Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 28.07.2020 № 284/2020;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 19 мартындагы 40 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 18.12.2020 № 686/2020;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 19 мартындагы 40 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 03.11.2021 № 612/2021;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 19 мартындагы 40 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 02.02.2022 № 24/2022.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы С.В. Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының _____ елның «__» ______ _________ номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча, аерым алганда: эчәргә яраклы суга, техник суга, су транспортлауга, су китерүгә тарифларны (мондый тарифны билгеләү кирәклеге турында карар кабул иткән җирле үзидарә органнары мөрәҗәгать иткән очракта), кайнар суга, кайнар суны транспортлауга, ташландык су агызуга ташландык су транспортлауга тарифларны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: Татарстан Республикасы территориясендә су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен хәл итүче, оешу-хокук формасына һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә оешмалар яки шәхси эшкуарлар (алга таба – җайга салынулы оешмалар).

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү (алга таба – тарифлар билгеләү).

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты, җайга салу органы).

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә (алга таба – күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтү каралмаган.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тарифлар билгеләү турында Дәүләт комитеты карары яки тарифларны билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында хат тора.

2.3.2. Тарифлар билгеләү турында Дәүләт комитеты карары реквизитлары:

тарифлар билгеләү турындагы карарның номеры һәм датасы;

тарифлар билгеләү турында карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме.

Тарифлар билгеләү турындагы эшне ачудан баш тарту турында хатның реквизитлары:

хатның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Дәүләт комитетына мөрәҗәгать итүнең үзе сайлаган ысулына ярашлы рәвештә бирелә (җибәрелә):

язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яки тапшыру турында хәбәр белән почта аша җибәрү юлы белән;

электрон рәвештә (мәгълүматны адресат раслый), шул исәптән «Федераль җайга салу органы - региональ җайга салу органнары - җайга салу субъектлары» бердәм мәгълүмат-аналитика системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша.

электрон рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына – http://uslugi.tatarstan.ru (алга таба – Дәүләт хезмәтләре порталы).

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы.

2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән, почта аша, «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте җайга салуның чираттагы хисап чоры башланыр алдыннан Дәүләт комитеты тарафыннан гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинет аша тапшырылган очракта, Дәүләт комитеты тарафыннан Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган гаризага эш номенклатурасы һәм «Документларны тикшерү» статусы нигезендә номер бирелгән көннән алып, бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган чираттагы исәп-хисап чоры башланганчы елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

2.4.2. Үзенә карата бәяләр (тарифлар) элегрәк дәүләт тарафыннан җайга салынмаган оешма өчен агымдагы елга бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдим агымдагы елның 1 ноябреннән соңга калмыйча тапшырылган очракта билгеләнә. Бу очракта оешма өчен тарифлар Дәүләт комитетына бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдимнәр һәм нигезләүче материаллар тулы күләмдә кергән көннән алып 30 календарь көн эчендә билгеләнә (әгәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән үзе, почта аша яки «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы аша бирелгән булса) яки Дәүләт хезмәтләре порталында шәхси кабинетта чагылдырыла торган эшләр номенклатурасы нигезендә гаризага номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелгән көннән алып 30 календарь көн эчендә билгеләнә (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт хезмәтләре порталында шәхси кабинет аша бирелгән булса). Дәүләт комитеты карары буенча күрсәтелгән срок 30 календарь көннән дә артмаска тиеш.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган тарифлар билгеләү турындагы эш ачудан баш тарту, мөрәҗәгать итүче тапшырган документларны һәм материалларны кире кайтарып, тарифлар билгеләү турында гариза теркәлгән вакыттан башлап 10 эш көне узганчы гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Дәүләт хезмәтләре порталында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru) түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар;

Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче, мөрәҗәгать категориясенә һәм нигезенә бәйсез рәвештә, гариза тапшыра:

- турыдан-туры Дәүләт комитетына яисә почта аша мөрәҗәгать иткәндә кәгазь чыганактагы документ рәвешендә (әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта);

- Дәүләт хезмәтләре порталы аша мөрәҗәгать иткәндә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле мәгълүмат кертү юлы белән тутырыла);

- «Электрон Татарстан» электрон документлар әйләнеше системасы аша мөрәҗәгать иткәндә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон рәвештә (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла).

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына мөрәҗәгать иткәндә гариза белән бергә нигезли торган түбәндәге материалларны тапшыра:

а) җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашырганда кулланыла торган күчемсез милек объектларына (биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, җир кишәрлекләренә) карата хокук билгели торган (граждани-хокукый килешүләрнең, консеция килешүләренең, юридик затны үзгәртеп корганда – тапшыру актларының күчермәләре), милекчелек хокукын раслый торган документларның күчермәләре, идарә итүнең башка законлы нигезе;

б) кушымталары белән бергә исәпкә алу сәясәтен раслау турындагы карарларның күчермәләре (синтетик һәм аналитик бухгалтерия исәпләрендәге счетларны һәм субсчетларны үз эченә алган счетларның расланган планын да кертеп);

в) ышаныч кәгазеннән башка гына оешма исеменнән эш итәргә хокуклы затны билгеләү (сайлау) турындагы документ күчермәсе;

г) алдагы җайга салуның 3 чоры һәм соңгы хисап датасы өчен бухгалтерлык һәм статистик хисаплылык күчермәләре;

д) билгеләнгән тәртиптә расланган производство программасының күчермәсе яисә, андагы производство программасын гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗларын исәпләмәләре белән бергә, әлеге ихтыяҗларны нигезләп һәм эшчәнлек төрләре буенча аңа кертелгән чыгымнарны аңлатып, производство программасы проекты;

е) җайга салынулы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга чыгымнар һәм, беренчел белешмәләргә икътисадый нигезләүне теркәп, җайга салынулы эшчәнлектән кирәкле тулай табыш (кулланыла торган исәпләмә индексларын, нормаларын һәм нормативларын, шулай ук тарифларны җайга салу алымын да күрсәтеп) һәм методик күрсәтмәләр нигезендә исәпләп чыгарылган озак сроклы

җайга салу параметрларының тәкъдим ителә торган күрсәткечләре яки кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яки) ташландык су агызуның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның дәүләт яки муниципаль милектәге аерым объектларына карата төзелгән концессия килешүендә билгеләнгән тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары күрсәткечләре исәпләмәсе;

ж) тарифлар күләме исәпләмәсе;

з) «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль законда каралган эшчәнлекнең җайга салынулы төрләре буенча аерым күрсәтелә торган хезмәтләр күләме исәпләмәсе, сугүткәргеч (канализация) челтәрләре буенча суны транспортлаганда суны шәхси куллану һәм югалту күләмнәрен нигезләп;

и) билгеләнгән тәртиптә расланган инвестиция программасы күчермәсе (булган очракта);

к) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә бәяләр билгеләү нигезләре нигезендә (алга таба – Бәяләр билгеләү нигезләре) җайга салуның элеккеге чорында җайга салынулы оешма өчен тарифлар билгеләгәндә исәпкә алынмаган өстәмә алынган керемнәр, (яки) алынмаган керемнәр һәм (яки) икътисадый нигезләнгән чыгымнар исәпләмәсен (булган очракта);

л) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итүче тарафыннан товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алынуын раслый торган документларның (сатып алулар турында нигезләмә, сатып алулар уздырылуы турында белдерү, сатып алу турындагы документлар, сатып алулар уздыру барышында төзелә торган сатып алуларны уздыру беркетмәләре) күчермәләре;

м) товарлар (эшләр, хезмәтләр) сату турында җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булган килешүләр (шул исәптән салкын су белән тәэмин итү, ташландык су агызу килешүләре, салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызуның бердәм килешүләре, кайнар су белән тәэмин итү килешүләре, кайнар суны, салкын суны транспортлау буенча килешүләр, тоташтыру (технологик ялгау) турындагы килешүләр) исемлеге, анда килешү төзелгән зат, килешү предметы, килешүне төзү датасы, килешүнең гамәлдә булу чоры, килешү буенча сатыла торган товарлар (эшләр, хезмәтләр) күләме турында мәгълүматлар булырга тиеш. Дәүләт комитеты тарафыннан әлеге исемлектән килешү күчермәләре соратып алынырга мөмкин, аларны тапшыру вакыты Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә, ләкин җайга салынулы оешмага таләп килгән көннән башлап 10 эш көненнән дә азрак була алмый;

н) җайга салуның элеккеге озак сроклы чорында чыгымнарны киметү нәтиҗәсендә җайга салынулы оешма ирешкән чыгымнар экономиясен нигезли торган һәм су белән тәэмин итүнең (ташландык су агызуның) ышанычлылыгы һәм сыйфаты кимемәвен һәм инвестиция һәм (яки) производство программаларында (алар булган очракта) билгеләнгән таләпләрнең бозылмавын раслый торган материаллар;

о) чираттагы җайга салу чорына материаллар, чимал, ягулык һәм башка энергия ресурслары белән тәэмин итү, чит оешмалар тарафыннан эшләр башкарылуы, шул исәптән подрядчы оешмалар тарафыннан ремонт эшләрен башкару турында, мөлкәтне (җиһазларны, җир кишәрлекләрен) арендалау турындагы килешүләрнең (кушымталары белән) күчермәләре;

п) салкын суны транспортлауны һәм (яки) агынты суларны транспортлауны гамәлгә ашыручы җайга салынулы оешмалар өчен, – суүткәргеч һәм (яисә) канализация челтәрләренең озынлыгы, диаметры һәм салу шартлары, салкын су һәм (яисә) канализация челтәрләренең озынлыгы һәм (яисә) канализация челтәрләренең һәр үзәкләштерелгән системасы буенча салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) агып төшүче суларны транспортировкалауның күләме турында, чираттагы елга планлаштырылган транспортлана торган салкын су һәм (яки) агынты суларның күләмнәре, соңгы 3 елда транспортлана торган салкын су һәм (яки) агынты су күләмнәре турында белешмәләр;

р) эшчәнлек зонасында салкын суны транспортлауны, агынты суларны транспортлауны гамәлгә ашыручы оешмалар булган, алар өчен тарифлар аналогларны чагыштыру ысулын кулланып билгеләнә торган гарантияләүче оешмалар өчен, – салкын суны транспортлауга һәм (яки) агынты суларны транспортлауга гарантияләүче оешманың агымдагы чыгымнары күләмен исәпләү;

с) су үткәрү һәм (яки) канализация челтәрләренең һәм (яки) корылмаларының милекчесенең транзит оешмаларына кертү критерийларына туры килүен раслаучы документларның күчермәләре һәм башка мәгълүмат.

т) җайга салуның алдагы чорында Бәяләр кую нигезләренең 67 пунктындагы өченче абзацы нигезендә җайга салына торган оешма тарафыннан ирешелгән чыгымнарны экономияләү барлыкка килүен нигезләүче һәм су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең план күрсәткечләренә ирешүен һәм расланган инвестиция программасына кертелгән чараларны гамәлгә ашыруны раслый торган (шул исәптән билгеләнгән тәртиптә төзәтмәләр кертелгән) материаллар;

у) Бәя билгеләү нигезләренең 67 пунктының дүртенче абзацына ярашлы рәвештә җайга салу оешмасы тарафыннан ирешелгән чыгымнарны экономияләүне раслаучы материаллар.

2.6.3. Элек тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу башкарылмаган оешма өчен тарифлар билгеләнгәндә, әлеге Административ регламентның 2.6.2 пунктының «л» - «н» пунктчаларында күрсәтелгән документлар тарифларны билгеләү турындагы гаризага теркәлми. Җайга салуның озак сроклы чорының беренче елына тарифлар билгеләгәндә, үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызу системаларына, мондый системаларның дәүләт яки муниципаль милектә булган аерым объектларына карата концессия килешүе төзелгән җайга салынулы оешма тарафыннан тарифларны билгеләү турында гаризага әлеге Административ регламентның 2.6.2 пунктының «л»-«о» пунктчаларында күрсәтелгән документлар теркәлми.

Берләштерү, үзгәртеп кору яки тоташтыру формасында юридик затларны үзгәртү нәтиҗәсендә барлыкка китерелгән җайга салуны оешма өчен бәяләр (тарифлар) билгеләнгәндә әлеге Административ регламентның 2.6.2 пунктының «а», «г», «л», «м» һәм «о» пунктчалары нигезендә үзгәртеп корылган оешмага (үзгәртеп корылган оешмаларга) карата тапшырылган документлар һәм материаллар кулланылырга мөмкин.

Юридик затларны берләштерү яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп кору нәтиҗәсендә барлыкка килгән җайга салынулы оешма тарафыннан шулай ук мондый оешманың дәүләт теркәвенә алу датасына бухгалтерлык хисабы тапшырыла.

Үзләре өчен тарифларны билгеләү аналогларны чагыштыру ысулын кулланып гамәлгә ашырыла торган җайга салынулы оешмалар тарифлар билгеләү турындагы гаризага әлеге Административ регламентның 2.6.2 пунктының «е», «ж», «к», «л» һәм «н» пунктларында каралган материалларны беркетмәскә хокуклы.

2.6.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар алу таләп ителми.

2.6.5. Тарифлар билгеләү турындагы гариза җайга салынулы оешманың җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан имзалана, җайга салынулы оешманың мөһере (ул булган очракта) белән таныклана һәм теркәлә торган документлар һәм материаллар исемлеген үз эченә ала.

2.6.6. Тарифлар билгеләү турындагы эшне ачу өчен күрсәтелгән документлар һәм материаллар исемлеге тулы булып тора.

2.6.7. Җайга салынулы оешма инициативасы буенча, күрсәтелгән документлардан һәм материаллардан тыш, тарифлар билгеләү өчен мөһим булган башка документлар һәм материаллар, шул исәптән бәйсез экспертларның эксперт бәяләмәсе дә, тапшырыла ала.

2.6.8. Гаризага теркәп тапшырыла торган документлар һәм материаллар төп нөсхәдә яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәләрдә тапшырыла.

2.6.9. Тарифлар билгеләү турында гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.10. Тарифлар билгеләү турында тәкъдим җайга салу оешмасы тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тәкъдим ителергә мөмкин:

җайга салу органы җитәкчесе тарафыннан шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш иткән зат тарафыннан);

кулга тапшыру турында белдереп, теркәлгән документлар исемлеге белән почта юлламасы итеп.

2.6.11. Тарифлар билгеләү турындагы гариза шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Федераль җайга салу органы - региональ җайга салу органнары - җайга салу субъектлары» бердәм мәгълүмат-аналитика системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы һәм Дәүләт хезмәтләре порталы аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар документны һәм документтагы битләр санын ачыклау мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.6.12. Җайга салынулы оешма, чираттагы җайга салу чорына кадәр, елның 1 маена кадәр, җайга салу органына тарифлар билгеләү турында тәкъдим кертә.

2.6.13. Агымдагы елга тарифлар билгеләнгән очракта, элек тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешма өчен тарифлар билгеләү турындагы тәкъдим мондый оешма тарафыннан агымдагы елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

тарифлар билгеләү турында тәкъдим бирү срокларын үтәмәү;

Дәүләт комитетына әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында каралган документларны һәм материалларны тулы булмаган күләмдә тапшыру.

мөрәҗәгать итүченең су үткәрү һәм (яки) канализация челтәрләренең һәм (яки) корылмаларының милекчеләрен һәм (яки) аларның законлы хуҗаларын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 642 номерлы карары белән расланган Кайнар су белән тәэмин итү кагыйдәләрендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карары белән расланган Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу кагыйдәләрендә каралган транзит оешмаларына кертү критерийларына туры килмәве.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

Югарыда күрсәтелгән көтү вакытына төшке аш вакыты һәм эш вакыты булмаган вакыт кертелми.

Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

Кирәкле барлык документлары белән гариза килгән көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән тарифлар билгеләү турында гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.11.1. Тарифлар билгеләү турында гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза тапшырылган көнне Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинетта һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.11.2. Дәүләт комитеты, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мондый документларны яңадан кәгазьдә тапшыру зарурлыгыннан башка гына, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә һәм гаризаны терки.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

1) объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу шартлары;

2) объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

3) объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга объектларда ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

6) хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;

7) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;

8) хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада хезмәт күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, хезмәттән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;

9) инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;

10) дәүләт хезмәтен күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләре гамәлләренә прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булмау;

4) Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бинаның һәм бүлмәләрнең инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең файдалана алырлык булу күрсәткечләренә ирешү

5) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.2. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:

1) документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

2) Мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Дәүләт хезмәтләре порталында тулы мәгълүмат булуы;

4) электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

5) дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтләреннән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.13.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт хезмәтләре порталыннан алынырга мөмкин.

2.13.4. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Әлеге Административ регламентның 2.6.11 пункты нигезендә, шул исәптән Дәүләт хезмәтләре порталы аша, электрон документ формасында гариза бирү мөмкинлеге бар.

2.14.3. Дәүләт хезмәтләре порталы аша электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Дәүләт хезмәтләре порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Дәүләт хезмәтләре порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Дәүләт хезмәтләре порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Дәүләт хезмәтләре порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Дәүләт хезмәтләре порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.4. Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;

2) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

3) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

4) кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә 3 ай дәвамында.

2.14.4. Мөрәҗәгать итүчеләрне Дәүләт хезмәтләре порталы аша Дәүләт комитетына кабул итүгә яздыру гамәлгә ашырылмый.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Язма мөрәҗәгать буенча Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен җентекле рәвештә язмача аңлатып бирә һәм законнарда билгеләнгән срок эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрә. Җаваплар мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә «Федераль җайга салу органы - региональ җайга салу органнары - җайга салу субъектлары» бердәм мәгълүмат-аналитика системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм реестр язуларында бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү өчен вариантлар исемлеге, шул исәптән мондый дубликатны бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликаты бирелми.

3.3. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча юллау административ процедурасын тасвирлау

Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча җибәрү гамәлгә ашырылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) тарифлар билгеләү турында эш ачу яки тарифлар билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында карар кабул итү;

4) тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимгә экспертиза;

5) тарифлар билгеләү турында карар кабул итү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау;

7) техник хатаны төзәтү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү:

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Дәүләт комитетына шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача формада һәм (яисә) Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге (алга таба – Бүлек) белгече шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача һәм (яки) язмача мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә дә, шулай ук, кирәк булганда, гариза рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, мөрәҗәгать итүченең язмача һәм электрон почта аша килгән мөрәҗәгатеннән тыш, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүченең электрон почта аша килгән мөрәҗәгате буенча җавап мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша мөрәҗәгать кергән көннән соң җиде эш көне узганчы җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүченең язмача мөрәҗәгате буенча җавап мөрәҗәгать итүче адресына электрон документ әйләнеше системасы аша (мөрәҗәгать итүченең әлеге системага тоташтырылган очракта) яисә почта аша (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән системага тоташтырылмаган очракта) язма мөрәҗәгатьне теркәгән көннән җиде эш көне узганчы җавап җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның һәм тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләрдә консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.6. Гаризаны кабул итү һәм теркәү:

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат аша, почта аша, электрон документ әйләнеше системасы, Татарстан Республикасында ягулык-энергетика комплексы һәм торак-коммуналь хуҗалык оешмалары тарифларын фаразлауның һәм анализлауның бердәм мәгълүмат-аналитика системасы, Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы, Дәүләт хезмәтләре порталы аша Дәүләт комитетына гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6 пункты нигезендә аңа документлар һәм материаллар тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: җайга салынулы оешма тарафыннан бирелгән гариза.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Дәүләт хезмәтләре порталы аша электрон формада кабул итү

3.6.2.1. Дәүләт хезмәтләре порталы аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Дәүләт хезмәтләре порталында авторизация башкара;

Дәүләт хезмәтләре порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә;

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән мәгълүматның дөреслеген раслый;

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: җайга салынган оешма тарафыннан Дәүләт хезмәтләре порталы аша бирелгән гариза.

3.6.3. Дәүләт комитетына документлар рәвешендә кергән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен документларны кабул итү

3.6.3.1. Гаризаны документлар рәвешендә бирү өчен мөрәҗәгать итүче әлеге Административ регламентның 2.6 пункты нигезендә документлар комплектын формалаштыра һәм гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлегенә (алга таба – эш башкару бүлеге) шәхсән үзе тапшыра, яисә почта юлламасы белән җибәрә.

3.6.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар комплектын карау

3.6.4.1. Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече:

гаризаны кабул итә;

гаризаны беренчел эшкәртә һәм, теркәлү номеры беркетеп һәм кабул итү көнен күрсәтеп, гаризаны электрон документ әйләнеше системасында терки;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы, кабул иткәндә бирелгән номеры турында тамга белән гариза күчермәсен тапшыра (кәгазь чыганакта гариза бирелгән очракта), яисә Дәүләт хезмәтләре порталына мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрә (гариза Дәүләт хезмәтләре порталы аша бирелгән очракта).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза.

3.6.4.2. Тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм алып бару бүлеге белгече гаризаны электрон документ әйләнеше системасы аша электрон формада рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрелгән гариза.

3.6.4.3. Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) гаризаны карап тикшерә һәм су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны җайга салу мәсьәләләрен алып баручы рәис урынбасарына (алга таба – рәис урынбасары) карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәис урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза.

3.6.4.4. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм Бүлек башлыгына карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек җитәкчесенә карап тикшерүгә җибәрелгән

гариза.

3.6.4.5. Бүлек башлыгы гаризаны карый, җаваплы башкаручыны билгели һәм карау өчен аңа җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җаваплы башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.6.4.6. Җаваплы башкаручы документларның әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән исемлеккә туры килү-килмәве буенча һәм документларның дөрес рәсмиләштерелгән булу-булмавын: комплектлылыгын, таныклый торган реквизитлары (имза, штамп, теркәлү номеры) булуын, гариза тутыруның төгәл булу-булмавын тикшерә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерелгән документлар.

3.7. Тарифлар билгеләү турында эш ачу яки тарифлар билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында карар кабул итү:

3.7.1. Әлеге Административ регламентның 2.8.2 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, тарифлар билгеләү турында карар проектын әзерләү өчен җаваплы бүлек хезмәткәре, эш буенча вәкаләтле вәкилне күрсәтеп, тарифлар билгеләү турында эшне ачу турында боерык проектын әзерли һәм аны Бүлек башлыгына, юридик бүлек башлыгына, рәис урынбасарына килештерү өчен җибәрә.

Бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы, рәис урынбасары тарифлар билгеләү турында эш ачу турындагы боерык проектын карый, килештерә. Тарифлар билгеләү турында эш ачу турындагы боерык проектын килештергәннән соң, рәис урынбасары тарафыннан әлеге документ килештерү өчен рәискә җиткерелә.

Рәис, тарифлар билгеләү турында эш ачу турындагы боерык проектын карап, аны имзалау турында карар кабул итә.

Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече тарифлар билгеләү турында эш ачу турындагы боерыкны терки.

Тарифлар билгеләү турында эш ачу турындагы боерык проектын әзерләү өчен җаваплы Бүлек хезмәткәре тарифлар билгеләү турында хат проекты әзерли һәм килештерү өчен аны Бүлек башлыгына, рәис урынбасарына имзалау өчен җибәрә.

Бүлек башлыгы тарифлар билгеләү турында эш ачу турында хат проектын карый, килештерә.

Рәис урынбасары, тарифлар билгеләү турында эш ачу турында хат проектын карап, аны имзалау турында карар кабул итә.

Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече эш ачу турында хатны терки һәм аны заказлы почта юлламасы итеп мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тарифлар билгеләү турында эш ачу турында боерык, мөрәҗәгать итүче адресына эш ачу турында хат.

3.7.2. Әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында билгеләнгән нигезләр булган очракта, җаваплы башкаручы тарифлар билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында хат проектын әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Бүлек җитәкчесе баш тарту турында хатны карый, килештерә һәм рәис урынбасарына килештерү өчен җибәрә.

Рәис урынбасары, баш тарту турында хатны карап, аны имзалау турында карар кабул итә.

Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече баш тарту турында хатны терки һәм аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура тарифларны билгеләү турында гариза теркәлгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: тарифлар билгеләү турындагы эшне ачудан баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хат.

3.8. Тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимгә экспертиза

Тарифлар билгеләү турында эш ачылган очракта, эш буенча вәкаләтле вәкил тариф исәпләнгәндә исәпкә алынган чыгымнарның нигезлелеге, тариф исәпләү параметрларын төгәл билгеләү өлешендә тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимгә экспертиза үткәрә, аның нәтиҗәләрен эксперт бәяләмәсендә чагылдыра, ул тарифларны билгеләү турындагы эшкә теркәлә.

Эксперт бәяләмәсе Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны җайга салу органының эксперт бәяләмәсенең үрнәк формаларын раслау турында» 2022 елның 23 мартындагы 237/22 номерлы  боерыгы белән расланган эксперт бәяләмәсенең үрнәк формасына ярашлы төзелә.

Эксперт бәяләмәсе «Федераль җайга салу органы - региональ җайга салу органнары - җайга салу субъектлары» бердәм мәгълүмат-аналитика системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып формалаштырыла.

Җайга салынулы оешмалар тарафыннан тарифлар билгеләү турында тапшырылган тәкъдимнәрне анализлау барышында тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимнәрне төгәенләштерү зарурлыгы барлыкка килсә, җайга салу органы өстәмә белешмәләр соратып ала, шул исәптән җайга салынулы оешма тарафыннан алдагы җайга салу чорында фактта тотылган чыгымнарны раслый торганнарын да. Мондый мәгълүматларны тапшыру срогы тарифларны җайга салу органы тарафыннан билгеләнә, ләкин җайга салынулы оешмага таләп алынган көннән башлап 7 эш көненнән дә ким булмаска тиеш. Өстәмә мәгълүматлар сорату зарурлыгы тарифларны җайга салу органы тарафыннан тарифлар билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып тормый.

Җайга салынулы оешма агымдагы елның 1 декабренә кадәр, әмма тарифлар билгеләү турында карар кабул ителә торган тарифларны җайга салу органы идарәсе (коллегиясе) утырышы узганчыга кадәр 7 нче календарь көннән дә соңга калмыйча, Дәүләт комитетына үз ихтыяры белән тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимнәргә өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

Эксперт бәяләмәсе килештерү өчен Бүлек башлыгына һәм рәис урынбасарына тапшырыла. Эксперт бәяләмәсен Бүлек башлыгы һәм рәис урынбасары тарафыннан килештерү нәтиҗәләре буенча эш буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны килештерү кәгазе төзелә, ул, эксперт бәяләмәсен теркәп (мөрәҗәгать итүче соравы буенча) электрон почта аша килештерү өчен мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура тарифлар билгеләнә торган җайга салу чоры башланачак елның 1 декабреннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Үзләренә карата элегрәк тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган мөрәҗәгать итүчеләр өчен, шулай ук үзләренә карата элегрәк тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган аерым оешмаларга су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызу өлкәсендәге җайга салынулы аерым эшчәнлек төрләренә тарифлар билгеләнгән очракта әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза Дәүләт комитетына килгән көннән башлап 20 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт комитеты карары буенча әлеге вакыт 30 календарь көненә озайтылырга мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: эксперт бәяләмәсе, су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны килештерү кәгазе.

3.9. Тарифлар билгеләү турында карар кабул итү.

3.9.1. Тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимгә экспертиза нәтиҗәләре буенча җаваплы бүлек хезмәткәре тарифлар билгеләү турында карар проектын, аңлатма язуын әзерли һәм алга таба Эшче тариф комиссиясе утырышында карау өчен бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы, рәис урынбасары белән килештерә.

Процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тарифлар билгеләү турында әзерләнгән карар проекты, аңлатма язуы.

3.9.2. Тарифлар билгеләү турында карар проекты Дәүләт комитетының Эшче тариф комиссиясе утырышында «Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карарлар кабул итү регламентын һәм тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының башка карарларын кабул итү регламентын раслау турында» 2021 елның 22 июлендәге пр-450/2021 номерлы боерыгында каралган тәртиптә һәм срокларда карала  (алга таба – Карарлар кабул итү регламенты).

Дәүләт комитеты һәм җайга салына торган оешма, дәүләт хакимиятенең мәнфәгатьле башкарма органы, җирле үзидарә органы арасында карар проекты буенча каршылыклар булмаса, килештерү кәгазенә имза салына, һәм карар проекты Дәүләт комитеты идарәсе утырышына чыгарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Эшче тариф комиссиясе беркетмәсе, имзаланган килештерү кәгазе һәм тарифлар билгеләү турында карар проекты.

Карар проекты буенча каршылыклар булса, җайга салына торган оешма, дәүләт хакимиятенең мәнфәгатьле башкарма органы, җирле үзидарә органы рәсми рәвештә Дәүләт комитеты һәм җайга салына торган оешма, дәүләт хакимиятенең башкарма органы, җирле үзидарә органы (алга таба – каршылыклар) Карарлар кабул итү регламентында расланган форма буенча  каршылыкларны алга таба Каршылыкларны карау комиссиясе утырышында карау өчен Дәүләт комитетына тапшыра.

Каршылыклар Карарлар кабул итү регламентында каралган тәртиптә һәм срокларда Каршылыкларны карау буенча комиссия утырышында карала.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә утырышына чыгарылган карар.

3.9.3. Тарифлар билгеләү турында карар Дәүләт комитеты идарәсе утырышында «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең эшчәнлек тәртибен һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышында карау өчен мәсьәләләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2010 елның 26 августындагы 231 номерлы Дәүләт комитеты боерыгында каралган тәртиптә кабул ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура тарифлар билгеләнә торган җайга салу чоры башланачак елның 20 декабреннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Үзләренә карата элегрәк тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган мөрәҗәгать итүчеләр өчен, шулай ук үзләренә карата элегрәк тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган аерым оешмаларга су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызу өлкәсендәге җайга салынулы аерым эшчәнлек төрләренә тарифлар билгеләнгән очракта әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза Дәүләт комитетына килгән көннән башлап 30 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт комитеты карары буенча әлеге вакыт 30 календарь көнгә озайтылырга мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: тарифлар билгеләү турында карар, Дәүләт комитеты идарәсе утырышы беркетмәсе.

3.10. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

3.10.1. Тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм алып бару бүлеге белгече Дәүләт комитеты идарәсе беркетмәсеннән өземтә һәм тарифлар билгеләү турында карарның расланган күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Күрсәтелгән документларны җибәрү почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән яки электрон рәвештә (мәгълүматны адресат раслый), шул исәптән «Федераль җайга салу органы - региональ җайга салу органнары - җайга салу субъектлары» бердәм мәгълүмат-аналитика системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң җиде эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә юлланган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

3.10.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен Дәүләт хезмәтләре порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон үрнәге шәхси кабинетка җибәрелә.

3.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Административ регламентка 2 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мәгълүматларындагы техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, электрон почта ярдәмендә яисә электрон документ әйләнеше системасы, яисә Дәүләт хезмәтләре порталы аша җибәрелә.

3.11.1. Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза.

3.11.2. Тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм алып бару бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны электрон документ

әйләнеше системасы аша электрон формада рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрелгән техник хатаны төзәтү турындагы гариза.

3.11.3. Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карау өчен рәис урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәис урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза.

3.11.4. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм Бүлек башлыгына карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек җитәкчесенә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.11.5. Бүлек башлыгы гаризаны карый һәм карау өчен җаваплы башкаручыга җибәрә.

3.11.6. Бүлек белгече документларны карый һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (почта яки электрон адрес буенча җибәрелгән) җавап.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының әлеге Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган заты һәм рәис урынбасары тарафыннан әлеге Административ регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруга карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы тикшереп тору Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларның Административ регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Административ регламентны үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләү.

4.5. Административ регламентны үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Дәүләт комитеты актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Дәүләт комитетының еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләр бозылуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затлар Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.8. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, әлеге административ регламентны үтәү өчен җаваплы булып, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.9. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Дәүләт комитеты эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитеты, Дәүләт комитеты вазыйфаи заты яисә Дәүләт комитетының дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт комитетына шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә рәис карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә Монополиягә каршы федераль хезмәткә тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматлар тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тарту;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда Мөрәҗәгать итүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Интернет-кабул итү, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре порталы, Бердәм портал аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм

гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты, аның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне теркәү чоры – ул алынган көннән соңгы эш көне узганчы.

Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә карала һәм Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6. 5.6 пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта әлеге пунктта күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт граждан хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 416-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Оешманың фирма бланкында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә

_______________________________
(инициаллары, фамилиясе)

**ТАРИФЛАР БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА ГАРИЗА**

Мөрәҗәгать итүче ____________________________________
(Мөрәҗәгать итүче - юридик затның уставка ярашлы фирма атамасы)

Оешма реквизитлары:______________________________________________________
(ИНН, КПП, ОКПО, ОКАТО, ОКОГУ)

__________________________________________________________________________.
(ОГРН, аны беркетү датасы һәм юридик затны теркәү турында карар кабул иткән органның исеме (юридик зат буларак дәүләт теркәве турында таныклык нигезендә)

Юридик адрес:_______________________________________________________

Почта адресы:__________________________________________________________

Җайга салынулы оешманың идарә органнарының урнашу урыннарының факттагы адресы: ___________________________________________________________________

Оешма җитәкчесе:___________________________________________________
(Ф.И.А.)

Элемтә өчен телефоннар (мәҗбүри); электрон почта адреслары, рәсми сайт

(булган очракта):_________________________________________________________

Тарифлар билгеләү өчен нигезләр:_________________________________________

__________________________________________________________________________.

Җайга салынулы товар һәм хезмәт күрсәтү төрләре:__________________________________________

Җайга салу алымы: _____________________________________________________

Җайга салу чоры: ____________________________________________________

Тарифларны җайга салу алымын сайлауның максатка ярашлы булуын нигезләү: __________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________.

Чираттагы җайга салу чорына исәпләнгән тариф күләме (җайга салу чоры бер календарь елыннан артып киткән очракта, һәр календарь елына исәпләнгән тарифлар күләмен чагылдырырга кирәк)

_______________________________________________________________________________

Кушымта: Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына тапшырылган материаллар реестры (битләрен нумерацияләп).

Оешма җитәкчесе (тулы имза)

Оешма мөһере
*(булган очракта)*

Дата

Башкаручы – фамилия, исем, ата исеме
Элемтә өчен телефоны

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә

________________________________

(инициаллары, фамилиясе)

Техник хата төзәтү турында гариза

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының ____________________ № ___ карарындагы хата турында хәбәр итәм, ул су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән.

Язылган:_______________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ____________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган карарга тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1. ____________________________________________________________________;
2. ____________________________________________________________________;
3. ____________________________________________________________________.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны:

түбәндәге адреска документ җибәрү юлы белән: ____________________;

_________________________________________________________________ адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Рәис<br>Груничев Александр Станиславович | 8 (843) 221-82-18 | кt@tatar.ru |
| Рәиснең беренче урынбасары<br>Хәбибуллина Лариса Васильевна | 8 (843) 221-82-66 | Larisa.Habibullina@tatar.ru |
| Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге башлыгы<br>Белалеева Нәфисә Равил кызы | 8 (843) 221-82-71 | Naficya.Belaleeva@tatar.ru |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге башлыгы<br>Салихов Фаил Фатыйх улы | 8 (843) 264-76-02 | Fail.Salihov@tatar.ru |

Монополиягә каршы федераль хезмәт

Элемтә өчен телефон: 8 (499) 755-23-23, электрон адрес: delo@fas.gov.ru.